КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 19 июль г.Казань № 599

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Икътисадның аерым тармаклары хезмәткәрләренең хезмәт урынындагы җир кишәрлегенә хокукы булган категорияләре турында» 2014 ел, 21 июль, 514 нче карарына үзгәреш кертү һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарлары үз көчен югалткан дип тану хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Икътисадның аерым тармаклары хезмәткәрләренең хезмәт урынындагы җир кишәрлегенә хокукы булган категорияләре турында» 2014 ел, 21 июль, 514 нче карарына, икенче абзацта «вакытлы» сүзен төшереп калдырып, үзгәреш кертергә.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының түбәндәге карарлары үз көчен югалткан дип танырга:

«Запас җирләре турында» 2002 ел, 23 гыйнвар, 25 нче;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү һәм аларны үз көчен югалткан дип тану турында» 2004 ел, 28 май, 257 нче;

«Җир кишәрлекләрен сайлау турындагы гаризаларны карау һәм Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына объектлар урнаштыру урыннарын алдан килештерү турындагы карарларны кабул итү вәкаләтләрен тапшыру турында» 2004 ел, 26 июль, 348 нче.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин